**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2018 елның 30 ноябре 27№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Яңа Үргәагар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә 2018 елның 19 ноябрендәге 25 номерлы «Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Иске Коратаавыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге гражданнарының кушымтада бирелә торган үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Кората авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Н.В. Кузнецов

Иске Кората авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 27
номерлы карарына 1
нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү киләсе календарь елның 1 гыйнварына кадәр җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Иске Коратаавыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 18 яшькә җитмәгәннәр, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына Иске Үргәгар авылы, Иске Үргәагар һәм Яңа Ургәагар авылы мәгълүмат стендларында һәм Әлки муниципаль районы http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтының Иске Кората авыл җирлеге битендә басылып чыгу һәм халыкка игълан итү юлы, шулай ук кәгазьдә имзалатып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллама белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Иске Коратаавыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) башкаруга исәп-хисап ясау хокукына ия оешма аша яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы аша акча күчерү юлы белән башкарыла

6.Түләү фактын касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Иске Кората авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 27
номерлы карарына 2
нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ______ №
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
__________________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүченең Ф.И.О. _________________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________
Нигездә:___________________________________________________________
Сезгә бер тапкыр түләнә торган түләүне_______________________ вакыты җиткәнче түләргә кирәк
_____________________________________________ сум күләмендә
реквизитлар :______________________________________________________
Алучының банкы БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № __________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләмәсе
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________

Җитәкче __________________ _______________________
М.У. (имза) (имзаны җәелдерү)

**кисү линиясе**- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә № __________________
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
__________________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)
суммада __________________ сум.
Түләүче Ф.И.О.
_________________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________
Алдым 20___ ел. "__" __________________ _______________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Киселгән өлеше хәбәрнамә тапшырылса, тутырыла һәм Иске Коратаавыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*